ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**___31.07.2019__________** **Чистай шәһәре** **№ 399**

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
башкарма комитетының
2019 ел, 21 март, 146 нчы карарына
үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе халыклары телләре турында”гы 1991 елның 25 октябрендәге 1807-1 номерлы Россия Федерациясе Законы нигезендә, “Россия Федерациясенең дәүләт теле турында”гы 2005 елның 1 июнендәге 53-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында"гы 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы законына нигезләнеп, “Татарстан Республикасы дәүләт теле буларак татар телен куллану” турындагы 12.01.2013 № 1-ТРЗ Татарстан Республикасы законына таянып, Россия Федерациясе Президентының «2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясенең дәүләт милли сәясәте стратегиясе турында" 2012 елның 19 декабрендәге 1666 номерлы Указы белән, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте концепциясен раслау турында»гы 2008 елның 3 июлендәге ПУ-312 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 27 июнендәге 451 номерлы «Татарстан Республикасы телләре турындагы законнарны гамәлгә ашыру буенча алга таба чаралар турында»гы карары нигезендә, Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү, үстерү һәм аларның функциональлеген арттыру өчен шартлар тудыру максатыннан, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**Карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 21 мартындагы 146 номерлы карарының 2 пунктына үзгәрешләр кертергә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында

телләр турындагы законнарны гамәлгә ашыру буенча комиссия составын раслап, кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә (О. В. Купцова) әлеге карарны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында http://chistopol.tatarstan.ru/ һәм хокукый мәгълүмат рәсми интернет-порталында https://pravo.tatarstan.ru/ урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Г. Ю. Задворнованы йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында телләр турындагы законнарны гамәлгә ашыру буенча**

**Комиссия составы**

**Г.Ю.Задворнова,** Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, комиссия рәисе;

**О.В.Купцова,** Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең мәгариф буенча урынбасары – Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе башлыгы, комиссия рәисе урынбасары;

**Э.Г.Таһирова,** Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф Идарәсенең баш белгече, комиссия сәркатибе.

**Комиссия әгъзалары:**

**Г.А.Нәбиуллин,** “Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты» республика сәяси оешмасының Чистай оешмасы рәисе (килешү буенча);

**Ч.А.Хаматова,** Чистай муниципаль районы Советының иҗтимагый оешмалар, ММЧ һәм милләтара мөнәсәбәтләр бүлеге башлыгы (килешү буенча);

**Н.В.Ларионова,** Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге башлыгы;

**Д.М.Хәсәнов,** Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре бүлеге башлыгы;

**И.П.Чурин,** Татарстан Республикасы керәшеннәр иҗтимагый оешмасының Чистай бүлеге Советы Рәисе (килешү буенча);

**П.В. Плотников,** Чистай шәһәре һәм Чистай районы Чуаш иҗтимагый үзәге рәисе(килешү буенча);

**В.А.Пономарев,** "Урыс иҗтимагый берләшмәсе" иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча);

**О.В.Добронравова,** Татарстан халыклары ассамблеясенең Чистай муниципаль районындагы вәкиллеге җитәкчесе (килешү буенча).